КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 6 июль г.Казань № 460

Татарстан Республикасында каты көнкүреш калдыклары белән эш итү мәсьәләләре буенча ведомствоара эшче төркем турында нигезләмәне һәм аның составын раслау хакында

Татарстан Республикасында каты көнкүреш калдыклары белән эш итүнең яңа системасына күчүне оештыруны тәэмин итү, каты көнкүреш калдыклары белән эш итү өлкәсендә законнарны камилләштерү, 2017 елның 5 июнендәге 385-ПРМ-АЧ номерлы Каты көнкүреш калдыклары белән эш итү өлкәсендә законнарны камилләштерү мәсьәләләре буенча ведомствоара эшче төркем кысаларында бөтенроссия киңәшмәсе беркетмәсенең 2.1 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасында каты көнкүреш калдыклары белән эш итү мәсьәләләре буенча ведомствоара эшче төркем (алга таба – эшче төркем) төзергә.

2. Карарга теркәлгән Татарстан Республикасында каты көнкүреш калдыклары белән эш итү мәсьәләләре буенча ведомствоара эшче төркем турында нигезләмәне һәм аның составын расларга.

3. Эшче төркемгә әлеге карар кабул ителгән көннән соң ике атна эчендә Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы эшләгән үрнәк форма буенча Татарстан Республикасында каты көнкүреш калдыклары белән эш итүнең яңа системасына күчүнең актуальләштерелгән «юл картасы» проектын әзерләргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2017 ел, 6 июль, 460 нчы
карары белән расланды

Татарстан Республикасында каты көнкүреш калдыклары белән эш итү мәсьәләләре буенча ведомствоара эшче төркем турында нигезләмә

1. Татарстан Республикасында каты көнкүреш калдыклары белән эш итү мәсьәләләре буенча ведомствоара эшче төркем (алга таба – эшче төркем) Татарстан Республикасында каты көнкүреш калдыклары белән эш итүнең яңа системасына күчү һәм каты көнкүреш калдыклары белән эш итү өлкәсендә законнарны камилләштерү белән бәйле мәсьәләләрне оператив һәм нәтиҗәле хәл итү максатларында оештырылган.

2. Эшче төркем Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән төзелә.

3. Эшче төркем үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таянып эш итә.

4. Үз эшчәнлекләрен эшче төркем әгъзалары түләүсез нигездә гамәлгә ашыра.

5. Эшче төркемнең төп бурычлары түбәндәгеләр:

каты көнкүреш калдыклары белән эш итүнең яңа системасына күчү буенча тәкъдимнәрне эшләү, бәяләү һәм анализлау;

Татарстан Республикасының калдыклар, шул исәптән каты калдыклар белән эш итү өлкәсендә территориаль схемасы белән билгеләнгән эшчәнлек зоналарында каты көнкүреш калдыклары белән эш итү буенча төбәк операторларын конкурс нигезендә сайлап алу процедураларын үткәрү өчен шартлар тәэмин итү;

каты көнкүреш калдыклары белән эш итүнең яңа системасына күчүне тәэмин итүгә һәм каты көнкүреш калдыклары белән эш итү буенча төбәк операторлары эшчәнлеген җайга салуга юнәлгән, кирәкле Татарстан Республикасы норматив хокукый актларын кабул итү турында тәкъдимнәр әзерләү;

коммуналь инфраструктура системаларына мөнәсәбәттә концессия килешүләре төзү һәм каты көнкүреш калдыклары белән эш итү өчен файдаланыла торган объектлар төзелеше белән бәйле мәсьәләләрне хәл итү;

каты көнкүреш калдыклары белән эш итү һәм каты көнкүреш калдыклары белән эш итү өчен файдаланыла торган коммуналь инфраструктура объектларын төзү буенча эшчәнлекне оештыру өлкәсендә бүтән мәсьәләләрне хәл итү.

6. Эшче төркем түбәндәгеләргә хокуклы:

үз утырышларында үзенең компетенциясенә карый торган мәсьәләләрне карап тикшерергә һәм алар буенча карарлар кабул итәргә;

билгеләнгән тәртиптә эш өчен кирәкле статистик һәм мәгълүмати материаллар алырга;

Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарыннан һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарыннан, каты көнкүреш калдыклары белән эш итү өчен файдаланыла торган коммуналь инфраструктура объектлары төзелеше заказчыларыннан билгеләнгән тәртиптә аның компетенциясенә караган мәгълүматны соратып алырга;

аның эшендә катнашырга билгеләнгән тәртиптә аудитор, фәнни-тикшеренү, җитештерү берләшмәләрен һәм предприятиеләрне, галимнәр һәм белгечләрне җәлеп итәргә;

аның компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары вәкилләрен һәм эшче төркем әгъзаларын тыңлау өчен чакырырга.

7. Эшче төркем үз эшчәнлеген коллегиаль нигездә гамәлгә ашыра.

8. Эшче төркем утырышын үткәрү турында карар эшче төркем җитәкчесе тарафыннан кабул ителә. Эшче төркем җитәкчесе карары белән эшче төркем утырышында, киңәшү тавышы белән, аның составына керми торган затлар катнаша ала.

9. Эшче төркем утырышы аның җитәкчесе тарафыннан оештырыла, кирәк булган саен үткәрелә, әмма айга кимендә бер тапкыр, һәм аның эшендә эшче төркем составының яртысыннан артыгы катнашса, тулы хокуклы булып санала.

10. Эшче төркем карарлары утырышта катнашкан эшче төркем әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән кабул ителә, беркетмә белән рәсмиләштерелә һәм составына вәкилләре кертелгән Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары өчен мәҗбүри характерда була. Утырыш беркетмәсе эшче төркем җитәкчесе тарафыннан имзалана һәм өч көн эчендә эшче төркемнең барлык әгъзалары адресына җибәрелә.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2017 ел, 6 июль, 460 нчы
карары белән расланды

Татарстан Республикасында каты көнкүреш калдыклары белән эш итү мәсьәләләре буенча ведомствоара эшче төркем
составы

| | |
|---|---|
| Нигъмәтуллин Рөстәм Камил улы | Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары, эшче төркем җитәкчесе |
| Сибгатуллин Илдар Нурзад улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Төзелеш, транспорт, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыклары идарәсе башлыгы, эшче төркем |

Эшче төркем әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Абдулганиев Фәрид Солтан улы | Татарстан Республикасы экология һәм табигый ресурслар министры |
| Абдуллин Ринат Әзһәр улы | Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча) |
| Барышев Александр Георгиевич | «Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре советы» ассоциациясе башкарма секретары (килешү буенча) |
| Заһидуллин Рөстәм Илдус улы | Татарстан Республикасы юстиция министры |
| Зарипов Марат Рифгать улы | Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе |
| Калинкин Денис Геннадьевич | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча) |
| Кәримов Альберт Әнвәр улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры |
| Трофимова Марина Викторовна | Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы (Татарстан) буена идарәсе җитәкчесе в.б. (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Фәйзуллин Ирек Әнвәр улы | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры |
| Хәйретдинов Фәрит Йосыф улы | Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буена идарәсе җитәкчесе (килешү буенча). |